Килешенде:
Татарстан
Республикасы
Яр Чаллы шәһәре
Мәгариф идарәсе
башлыгы

_______________
Н.В.Кашапов

Югары белем бирү федераль
дәүләт бюджет мәгариф
учреждениесе «Яр Чаллы
дәүләт педагогика
университеты" өстәмә һөнәри
белем бирү үзәге директоры

_______________
Л.Р.Шакирова

Раслыйм:
Муниципаль автономияле
гомуми белем бирү
учреждениесе "21 нче гомуми
урта белем бирү мәктәбе"
директоры

_______________
Р.Р.Калимуллин

Татар әдәбиятында һәм сәнгатендә Габдулла Тукай премиясенә
ия булган шәхесләребез иҗаты буенча
II Республикакүләм фәнни-гамәли конференция
нигезләмәсе.

## I. Гомуми мәгълүмат

1.1. Нигезләмә Татар әдәбиятында һәм сәнгатендә Г.Тукай премиясенә ия булган шәхесләребез иҗаты буенчафәнни-гамәли конференция (алга таба - Конференция) үткәрү максатын, бурычларын, тәртибен билгели. Конференциянең үткәрү тәртибе, алымнары үзгәрергә мөмкин.

1.2. Конференция гомуми белем бирү оешмаларында туган (татар) тел һәм әдәбиятыннан башлангыч, төп һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә куючы педагогларны берләштерә.

## II. Конференциянең максаты һәм бурычлары

2.1. Туган (татар) тел һәм әдәбияты укытучыларын һәм укучыларны фәнни-эзләнү эшләренә тарту.

2.2. Бурычлары:

- Г.Тукай премиясенә ия булган шәхесләребезне барлау, укучыларны аларның иҗаты белән таныштыру;
- укучыларда телебезгә, милли гореф-гадәтләребезгә, рухи байлыгыбызга мәхәббәт тәрбияләү;
- татар халкының мәдәни-тарихи мирасын, туган як табигатен өйрәнүгә кызыксыну уяту;
- сәләтле балаларны ачыклау һәм аларның үсеше өчен шартлар тудыру;
- укытучыларның алдынгы тәҗрибәсен барлау, эзләнү эшенә тартып, аларны фәнни эшләргә җәлеп итү.
- республиканың төп һәм урта гомуми белем бирү мәктәпләре, гимназия укытучыларының һөнәри үсеш юлларын билгеләү, педагогик тәҗрибәне тарату.

## III. Конференцияне оештыручылар

3.1. Конференцияне оештыручылар:

- Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының мәгариф идарәсе;
- Югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе «Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты" өстәмә һөнәри белем бирү үзәге";
- Яр Чаллы шәһәре муниципаль бюджет учреждениесе "Мәгълүмати-методик үзәк";

- Яр Чаллы шәһәренең муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе “21 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”.

## IV. Конференциядә катнашучылар

4.1. Конференциядә гомуми белем бирү оешмаларының 5-11 сыйныф укучылары, урта гомуми белем бирү оешмаларының укытучылары, педагог-китапханәчеләре катнаша ала.

## V. Конференциянең эш юнәлешләре

5.1. Татар әдәбиятында һәм сәнгатендә Г.Тукай премиясенә ия булган шәхесләребез иҗаты:

Укучылар өчен:

1)1-6 нчы сыйныф укучылары өчен нәфис сүз (язучылар, шагыйрьләрнең Г.Тукай премиясен алган әсәрләре буенча);

2) 5-11 нче сыйныф укучылары өчен фәнни-гамәли эш.

Укытучылар өчен:

фәнни-гамәли эш, мастер-класс, видеодәрес, дәрес һәм дәрестән тыш чара планнары (чыгыш).

## VI. Фәнни-гамәли хезмәтләргә таләпләр

6.1. Фәнни-гамәли хезмәтләр түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш:

- чыгыш ясаучының теманы ачып бирә алуы;
- аргументлаштырылган һәм иҗади фикерләү сәләтенә ия булуы;
- грамоталы, әдәби телдә язылган булуы, мисал итеп китерелгән фактларның дөрес булуы шарт;
- хезмәтләрне күрсәтмә материаллар, презентацияләр белән баету;
- куелган проблема буенча әдәбият, чыганакларны куллану, эшләрдә сылтамалар дөрес куелу.

6.2.Фәнни-гамәли хезмәтләр, чыгышлар бары тик татар телендә генә кабул ителә.

6.3. Хезмәтнең язылу тәртибе.

Эш төзәтүләрсез, А4 форматында (шрифт Times New Roman-14, интервал 1,5, уңнан-1,5; сулдан-2,5 астан-2; өстән-1,5) компьютерда басылган булырга тиеш. Эзләнү эшләре папкага тегелеп тапшырыла һәм кире кайтарылмый.

Титул битенә белем бирү учреждениесенең тулы исеме, район, катнашучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, сыйныфы, тема, эшнең юнәлеше һәм җитәкчесенең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме языла.

Кереш, йомгак, әдәбият исемлеге, төп өлешнең аерым бүлекләре яңа биттән башлана.

Кулланылган әдәбият исемлеге яңа юлдан алфавит тәртибендә языла.

6.4. Тезисларның калыбы түбәндәгечә булырга тиеш:

- фәнни-эзләнү эшенең төп фикерләре кыскача чагылыш таба;
- тикшерелгән, төзәтүләрсез була;
- компьютерда җыела, А4 форматындагы кәгазьнең бер ягына гына сыйфатлы итеп принтерда чыгарылган була;
- исеме уртага 14 нче шрифтны калынайтып языла, ахырда нокта куелмый;
- авторның исеме, фамилиясе тулаем күрсәтелә, мәктәбе, сыйныфы, фәнни җитәкчесенең фамилиясе 14 нче шрифт белән битнең уң як өлешенә языла;

- яңа юлдан башланучы фразалар кызыл юлдан 1 см калдырылып башлана.

Тезис исеме, авторы, фәнни җитәкчесе турындагы мәгълүматлар белән тезис тексты арасындагы ара 1 интервалны тәшкил итә.

Тезисларның күләме – 1 бит.

Тезислар электрон вариантта тапшырыла.

**<u>Искәрмәләр: </u>1. Конференциягә җибәрелгән хезмәтләр Г.Тукай премиясе алган әсәр буенча булырга тиеш.**

**2. Укучыларның фәнни эшләрендә автор һәм фәнни җитәкче бер генә булуы мөһим.**

**3. Республикакүләм башка конкурсларда катнашып призлы урын алган, матбугатта басылган эшләр кабул ителми.**

Эшләр электрон вариантта кабул ителә.

6.5. **<u>Чыгыш регламенты</u>** һәм бәяләү критерийлары.

Жюри әгъзалары укучыларның һәм укытучыларның тикшеренү эшләрен түбәндәге критерийлар буенча бәялиләр:

- проблеманы ачу тирәнлеге, бөтенлек, махсус техника һәм техниканы куллану;
- дөрес логикага буйсынган һәм исбатлау өлеше булган көчле аргументлар һәм нәтиҗәләр күрсәтү; фәнни эш; эш максатларын дөрес билгеләү;
- чыгышның композицион төгәллеге, үз фикереңнераслый белү, теманы ачу дәрәҗәсе;
- тәкъдим ителгән эшнең хәзерге заман шартларына туры килүе, күрсәтмә материалның булуы;
- аралашу һәм сөйләм культурасы.

Чыгышларның озынлыгы 5-7 минут. Чыгыш вакытында укучы төп уйларны һәм нәтиҗәләрне кыскача һәм ачык итеп күрсәтергә тиеш. Компьютер презентациясе хуплана.

6.6. Нәфис сүз бәяләү критерийлары

- дикция, интонация, уку сәнгатьлелеге;
- образга керү дәрәҗәсе;
- сөйләүченең гәүдә торышы, хәрәкәте, мимикасы;
- сөйләү темпының эчтәлеккә туры килүе;

Һәр пункт 5 балл системасында бәяләнә. Гомуми балл-20.

<u>Искәрмә:</u> жюри тарафыннан критерийлар тулыландырылырга мөмкин.

6.7. Эшләр электрон вариантта кабул ителә (икенче турга узучылар кәгазь вариантын алып киләләр).

## VII. Конференцияне үткәрү тәртибе

7.1. Оештыру комитеты конференциядә катнашу өчен гаризаларны сайлап алу хокукын үзендә калдыра.

7.2. Конференция Яр Чаллы шәһәренең муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе “21 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”ндә үткәрелә.

7.3. Конференция 2 этапта үткәрелә:

I этап – сайлап алу этабы. Фәнни-гамәли эшләрне, тезисларны, видеоязмаларны 2026 нчы елның 26 нчы апреленә кадәр **dgauhar75@mail.ru** электрон адресына авторның фамилиясен күрсәтеп, «Конференция» тамгасы белән **<u>архивлаштырмыйча</u>** җибәрергә. Фәнни-гамәли эштә, тезиста катнашучының исемен күрсәтергә. Күрсәтелгән вакыт узгач эшләр кабул ителми.

II этапка узучылар исемлеге 2026 нчы елның 27 нче апрелендә Яр Чаллы шәһәренең муниципаль автономияле гомуми белем бирү учреждениесе “21 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе”нең официаль сайтына эленә.

https://edu.tatar.ru/n_chelny/sch21chelny

Эшләренең кәгазь варианты чыгыш ясар алдыннан экспертлар комиссиясенә тапшырыла.

Элемтәгә керү өчен кәрәзле телефон: 89872389640 (татар теле һәм әдәбияты укытучысы Демухаметова Гәүһәр Фаяз кызы)

7.4. Конференциядә катнашу өчен, гариза-заявка түбәндәге формада җибәрелә: *кушымта №1*.

7.5. Конференциядә катнашу өчен 200 сум күләмендә (һәр эш өчен) оештыру взносы түләргә кирәк. Квитанция копияләрен гариза-заявка, фәнни эшләрне, тезислар белән бергә архивлаштырмыйча җибәрү сорала. Оештыру взносы дипломнар, сертификатлар, оештыру эшләре өчен тотыла: *кушымта №2*

## VIII. Конференцияне йомгаклау һәм нәтиҗә ясау

Республикакүләм фәнни-тикшеренү конференциядә катнашучыларның чыгышы алдан билгеләнгән критерийлар буенча бәяләнә.

Катнашучыларның чыгышларын тыңлап бетергәннән соң, эксперт комиссиясе утырышы үткәрелә һәм җиңүчеләр турында карар чыгарыла.

Эксперт комиссиясенең карары протоколлаштырыла.

Фәнни-гамәли конференциядә җиңүчеләргә дипломнар, сертификатлар, рәхмәт хатлары тапшырыла, катнашучыларга дипломнар 9 майга кадәр гаризада күрсәтелгән электрон адреска җибәрелә.

*Кушымта №1* ***(Анкетаны бары татарча тутырырга!!!)***

| | АНКЕТА | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Катнашучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (тулысынча) | Эшнең темасы | Юнәлеш | Оешма исеме (устав буенча), адресы, телефоны | электрон адрес | Элемтә өчен телефон (Укучы өчен фәнни җитәкче үз телефон номерын яза) | укучылар өчен – сыйныф, җитәкченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме |

*Кушымта №2*

РЕКВИЗИТЫ

| | |
|---|---|
| Полное наименование организации | Муниципальное автономное общеобразовательное учреждение города Набережные Челны «Средняя общеобразовательная школа № 21» |
| Краткое наименование организации | МАОУ «СОШ № 21» |
| Юридический адрес, фактический адрес | РТ, г. Набережные Челны, ул. Железнодорожников д. 65 |
| ИНН/КПП | 1650083359/165001001 |
| ОГРН | 1031616010030 |
| Расчетный счет | 03234643927300001100 |
| л/с | ЛАВ30800070-СОШ21 |
| Наименование банка | ОКЦ №6 ВВГУ БАНКА РОССИИ |
| Корреспондентский счет | 40102810445370000079 |
| БИК | 019205400 |